ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 60-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 60-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2025 елның 3 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2025 елның 7 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 232-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

# Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 2024 елның 8 августындагы 330-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләр (алга таба – креатив индустрия) өлкәсендә аерым мөнәсәбәтләрне җайга сала, шулай ук креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгели.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Креатив индустрияләр өлкәсендә хокукый җайга салу**

Креатив индустрияләр өлкәсендә хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4 статья. **Креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) креатив индустрияләр өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен тикшереп тору;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Креатив индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) креатив индустрияләр өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү (алга таба - вәкаләтле орган);

2) Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен, шул исәптән креатив индустрияләр субъектлары турында белешмәләрне күрсәтелгән реестрга кертү һәм аннан төшереп калдыру тәртибен билгеләү;

3) физик затларны, юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне креатив индустрияләр субъектларына кертү критерийларын билгеләү;

4) физик затларны, юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне креатив индустрияләр субъектларына кертүнең әлеге өлешнең 3 пункты нигезендә билгеләнгән критерийларына туры килүен раслау тәртибен билгеләү;

5) Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләрне билгеләү критерийларын билгеләү;

6) Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасы турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен билгеләү, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларында креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасы турында Федераль законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 4 пункты нигезендә расланган белешмәләрнең тип составын исәпкә алып, мондый белешмәләрнең составын раслау һәм мондый белешмәләрне урнаштыру;

7) Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасына караган Татарстан Республикасы мөлкәтен билгеләү;

8) Татарстан Республикасында креатив кластер төзегәндә файдаланыла торган Татарстан Республикасы мөлкәтен билгеләү;

9) креатив индустрияләр өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен оешмалар төзү;

10) креатив индустрияләр өлкәсендә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Креатив индустрияләр өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) физик затларның, юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең креатив индустрияләр субъектларына кертүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән критерийларына туры килүен раслауны гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару;

3) территориянең территорияне креатив кластер дип тану критерийларына туры килүен Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә раслауны гамәлгә ашыру;

4) Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләрне

билгеләүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән критерийлары нигезендә Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләр исемлеген төзү.

5) креатив индустрияләр өлкәсендә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган тарафыннан креатив индустрияләр өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен консультация бирү һәм (яисә) эксперт органнары төзелергә мөмкин.

5 статья. **Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестры**

1. Креатив индустрия субъекты турында белешмәләр Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрына кертелә.

2. Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрына кертелә торган креатив индустрияләр субъектлары турында белешмәләр составы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

3. Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрындагы белешмәләр Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә креатив индустрияләр субъектларының бердәм реестрына кертеләләр.

6 статья. **Креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасы**

1. Креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

2. Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасы турында белешмәләр әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 6 пункты нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Татарстан Республикасында креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасы турында белешмәләр креатив икътисад өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына күрсәтелгән орган билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

7 статья. **Креатив индустрияләр өлкәсендә дәүләт ярдәме чаралары**

1. Креатив индустрияләрне үстерү өчен уңай шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрына кертелгән һәм Федераль законның 10 статьясында билгеләнгән шартларга туры килә торган креатив индустрияләр субъектларына Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт ярдәме

чаралары күрсәтелергә мөмкин.

2. Креатив индустрияләр өлкәсендә дәүләт ярдәме креатив индустрияләр субъектларына финанс, мөлкәт, мәгариф, консультация бирү, мәгълүмати һәм башка төрле ярдәмнәр күрсәтү юлы белән башкарылырга мөмкин.

3. Креатив индустрияләр өлкәсендә финанс һәм (яисә) мөлкәти ярдәм алган креатив индустрияләр субъектлары тарафыннан Федераль законның 15 статьясы нигезендә тапшырылган белешмәләр Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрына кертелә.

8 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясендә креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 2024 елның 8 августындагы 330-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 330-ФЗ номерлы Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнгән.

330-ФЗ номерлы Федераль закон креатив икътисадны үстерүгә һәм гражданнарга иҗади һәм интеллектуаль потенциаллары нигезендә тормышта үзләрен табу өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән, креатив индустрия субъектларының эшчәнлек шартларын һәм дәүләт ярдәме рәвешләрен билгели.

330-ФЗ номерлы Федераль законда Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендәге вәкаләтләре каралган.

330-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында закон проекты тарафыннан Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне оештыруның һәм үстерүнең хокукый нигезләре билгеләнә.

Аерым алганда, креатив (иҗади) индустрияләр өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте вәкаләтләре, Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрын алып бару нигезләре, креатив индустрияләр өлкәсендә дәүләт ярдәме формалары һәм башка нигезләмәләр билгеләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының креатив индустрияләр өлкәсендәге вәкаләтләренә Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен, физик затларны, юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне креатив индустрияләр субъектларына кертү критерийларын билгеләүне, физик затларның, юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең креатив индустрияләр субъектларына кертү критерийларына туры килүен раслау тәртибен, Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләрне билгеләү критерийларын билгеләүне һәм башка вәкаләтләрне кертү күздә тотыла.

Креатив индустрияләр өлкәсендәге вәкаләтле органга физик затларның, юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең креатив индустрияләр субъектларына кертүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән критерийларына туры килүен раслауны гамәлгә ашыруны, Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив индустрияләр субъектлары реестрын булдыру һәм алып баруны, Татарстан Республикасында өстенлекле креатив индустрияләр исемлеген төзүне һәм креатив индустрияләр өлкәсендә башка вәкаләтләрне йөкләү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәрешләр кертү яки кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслау таләп ителәчәк:

Татарстан Республикасында эшчәнлек алып баручы креатив (иҗади) индустрияләр субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару тәртибен;

физик затларны, юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне креатив (иҗади) индустрияләр субъектларына кертү критерийларын;

физик затларның, юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең креатив (иҗади) индустрияләр субъектларына кертү критерийларына туры килүен раслау тәртибен;

Татарстан Республикасында өстенлекле креатив (иҗади) индустрияләрне билгеләү критерийларын;

Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасы турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен.

Моннан тыш, Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасына караган Татарстан Республикасы мөлкәтен һәм Татарстан Республикасында креатив кластер булдырганда кулланыла торган Татарстан Республикасы мөлкәтен билгеләү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Татарстан Республикасында креатив индустрияләр белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү яңалык түгел, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан «Город-RE'ACTOR» Бөтенроссия мультижанрлы креатив индустрияләр фестивале үткәрелә, «Татарстан Республикасы яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе арт-резиденцияләрнең төбәк челтәрен үстерү буенча эш алып бара, алар Татарстанның креатив яшьләренә ярдәм итү буенча системалы үзгәрешләргә юнәлдерелгән («REACTOR» арт-резиденциясе). Креатив индустрияләр өлкәсендәге эшчәнлекне «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе гамәлгә ашыра, «Югары технологияләр өлкәсендәге «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына инновацияләр өлкәсендә региональ конкурслар оештыруны һәм уздыруны үз эченә алган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтә. Күрсәтелгән учреждениеләр тарафыннан креатив индустрияләр өлкәсендәге вәкаләтләр гамәлгә ашырылачак.

Креатив индустрияләргә бәйле мәсьәләләр стратегия һәм программа документлары, шулай ук аларны үтәү өчен кабул ителгән гамәлгә ашыру планнары составына кертелгән. Креатив индустрия субъектларына дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүгә кагылышлы аерым нигезләмәләр субсидияләр бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларда, мәсәлән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 19 гыйнварындагы 29 номерлы һәм 2024 елның 15 ноябрендәге 1013 номерлы карарларында исәпкә алынган.

Закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджетыннан яңа чыгымнар күздә тотылмый, креатив эшчәнлек субъектларына карата ярдәм чаралары Татарстан Республикасы дәүләт программаларында каралган гамәлдәге ярдәм формалары кысаларында күрсәтеләчәк.

Законны кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итмәячәк.